## «Йөзек кашы» театр клубының уставы

**1.Гомуми бүлек.**

1. « Йөзек кашы» театры китапханә һәм китап укучыларның ирекле берләшмәсе.

1.2.Клубнын максаты- китапханәдә уздырылган һәр масса- чарада катнашу, әдәби композицияләр,пьесалардан өзекләр күрсәтү.

1.3.Клубның ин төп бурычы — берләшмә әгъзаларенең буш вакытларын файдалы итеп оештыру, аларның талантларын, сәләтләрен һәрьяклап үстерү һәм матур әдәбият белән таныштыру.

**2.Клуб әгъзаләренең хокуклары.**

2.1.Клуб әгъзаләре сценарий язу өчен пьеса яки әдәби әсәр тәкъдим итә алалар.

2.2.Клуб әгъзаләре булачак кичәдә роль башкаруга үзенең кандидатурасын тәъдим итә алалар.

2.3.Клуб әгъзаләре булачак кичәнең сценарийсына үз фикерләрен һәм өстәмәләрен тәкъдим итә алалар.

**3.Клуб әгъзаләренең вазифалары.**

3.1.Клуб әгъзаләре пьесадан өзекләрне күренекле даталарга яки ял кичәләрендә әзерләп күрсәтергә тиешләр.

**4.Кадрлар составы.**

4.1.Клубның җитәкчесе клуб эшчәнлеге белән идарә итә, катнашучыларга репетицияләрнең, кичәнең кайчан һәм кайда булуын хәбәр итә.

4.2.Рәссам белдерү әзерли һәм спектаклга декорацияләр ясый.

4.3.Музыка өлешен әзерләү һәм алып бару өчен җаваплы кеше була.

**5.Спектакльне әзерләү.**

5.1.Репетицияләр үзәк китапханәнең уку залында һәм башка бүлекләрдә булырга мөмкин.

5.2.Репетицияләрне клуб җитәкчесе күзәтеп үз фикерләрен әйтә ала.

5.3.Әзерләнгән кичә үзәк китапханәнен уку залында һәм башка урыннарда була ала.

6.**Хәзерге Устав яңадан редакцияләнә һәм кирәк булса өстәмәләр кертелә ала.**

***Театр. Сәхнә… Келт-келт итеп йөри,***
***Замананың иске сәгате.***
***Тарих сезне күккә чөяр әле,***
***Зурлаганыгыз өчен сәнгатьне!***

Тормыш – көнкүреш мәшәкатьләреннән аерылып, берничә сәгатькә генә булса да сәнгать дөньясында онытылу, адәм баласының күңелен нечкәртеп, уй-тойгыларын сафландырып җибәрә.

Ә менә күп санлы тамашачыларның күңелен әсир итәрлек сәләт ияләре санаулы гына, табигать биргән сәләтне тырышлык белән үстергәндә генә, алар халкыбызның йөзек кашына әверелә.

Менә шундыйларның берсе район авылара үзәк китапханә каршында 2007 елдан эшләп килүче ***«Йөзек кашы»*** театр клубы. Ул эшли башлаганнан бирле ел буена тамашачыларның күңелен җылытып, яктыртып тора.

Китапханәдә уздырылган һәр масса-чарада катнашып, аның эчтәлеген тулыландырып, тамашачы өчен кызыклырак, җанлырак итеп җибәрә. Язучылар иҗаты белән таныштырганда халыкның күңелләрен кузгалтырлык образлар тудыра.

***«Йөзек кашы»*** театр клубында шөгыльләнеп китапханә коллективы яшәүнең тәмен табып, оптимистик рухта калып, тулы канлы тормыш белән гомер итә.

Киләчәктә дә ***«Йөзек кашы»*** театр клубына рух күтәренкелеге белән озын, иҗади тормыш насыйп булсын иде.






ФОРМУЛЯР
ЧИТАТЕЛЯ
Фамилия
Имя, отчество
Национальность
Образование
Профессия


Гаилә белән укыйбыз




ларын уратып
Тарихта калган еллар